**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

29.06.2021 732-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибен раслау турында» 2014 елның 3 февралендәге 70-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибен раслау турында» 2014 елның 3 февралендәге 70-п номерлы боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык преамбуласында «, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләрне һәм аңа булган зарарлы физик йогынтыларның нормативлары турында» 2000 елның 2 мартындагы 183 номерлы карары» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта «стационар чыганаклардан» сүзләреннән соң «әлеге боерыкка кушымта нигезендә» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе» сүзләрен «Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм экологик мониторинг идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Р.И.Камалов» сүзләрен «А.М.Шиһапов» сүзләренә алмаштырырга;

боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

2 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын, 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 19 декабрендәге 1528-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты (алга таба – ДЭК регламенты) нигезендә.»;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның 6.1 пунктындагы беренче абзацында «Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе» сүзләрен «Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

8.4 пунктчада «әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлеге» сүзләрен «экологик нормалаштыру бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

8.6 пунктның беренче абзацында «Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру идарәсе» сүзләрен «Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм экологик мониторинг идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

8.7 пунктының беренче абзацында һәм алга таба текст буенча тиешле килеш кушымчаларында бирелгән «министрның беренче урынбасары» сүзләрен, тиешле килеш кушымчаларында кулланып, «министр урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1 нче һәм 2 нче кушымталарында «Министрның беренче урынбасары имзасы» сүзләрен «Министр урынбасары имзасы» сүзләренә алмаштырырга.

Министр А.В. Шадриков